Олыяз авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

«16» декабрь, 2019 ел № 24

Олыяз авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 елларның план чорына бюджеты турында

Олыяз авыл җирлеге башлыгы тәкъдим иткән Олыяз авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 елларның план чорына бюджеты проектын караганнан соң, Олыяз авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1 статья

1. 2020елга авыл җирлеге бюджетың төп характеристикаларын расларга:

1) авыл җирлеге бюджет керемнәренең фаразланыла торган гомуми күләме 2248000,00 сум тәшкил итә;

2) авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2248000,00 сум.

3) авыл җирлеге бюджеты кытлыгы (профициты) 0 сум күләмендә

2. 2021 елга һәм 2022 елга авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразланыла торган гомуми күләме 2021 елга 2292163,84 сум һәм 2022 елга 2333539,66 сум күләмендә;

2) авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2022 елга 2292163,84 сум һәм 2023 елга 2333539,66 сум.

3) авыл җирлеге бюджеты кытлыгы (профицит) 2021 елга 0 сум, 2022 елга 0 сум күләмендә.

3. Авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын билгеләргә:

2020 елга әлеге Карарга 1 нче кушымта нигезендә;

2021 елга һәм 2022 елга әлеге Карарга 2 нче кушымта нигезендә.

2 статья

1. 2020 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

муниципаль бурычның иң югары чиге авыл җирлеге бурыч йөкләмәләре буенча ноль сум күләмендә, шул исәптән, муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

2. 2021 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

муниципаль бурычның иң югары чиге авыл җирлеге бурыч йөкләмәләре буенча ноль сум күләмендә, шул исәптән, муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

3. 2022елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

муниципаль бурычның иң югары чиге авыл җирлеге бурыч йөкләмәләре буенча ноль сум күләмендә, шул исәптән, муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

4. Олыяз авыл җирлеге бюджетының муниципаль бурычының иң чик күләмен 2020 елга ноль сум күләмендә билгеләргә.

5. Олыяз авыл җирлегебюджетының муниципаль бурычының иң чик күләмен 2021 елга ноль сум күләмендә билгеләргә.

6. Олыяз авыл җирлеге бюджетының муниципаль бурычының иң чик күләмен 2022 елга ноль сум күләмендә билгеләргә.

7. 2020 елга муниципаль бурычка хезмәт күрсәтү чыгымнары күләмен ноль сум күләмендә билгеләргә.

8. 2021 елга муниципаль бурычка хезмәт күрсәтү чыгымнары күләмен ноль сум күләмендә билгеләргә.

9. 2022 елга муниципаль бурычка хезмәт күрсәтү чыгымнары күләмен ноль сум күләмендә билгеләргә.

3 статья

Авыл җирлеге бюджетында 2020 елга авыл җирлеге бюджетының фаразланыла торган керем күләмен әлеге Карарга 3 нче кушымта нигезендә һәм 2021, 2022 еллар план чорына әлеге Карарга 4 нче һәм 5 нче кушымталар нигезендә исәпкә алырга.

4 статья

2020 елга һәм 2021 һәм 2022 елларның план чорына авыл җирлеге бюджетының керемнәре түбәндәгеләр хисабына формалаша, дип билгеләргә:

1) Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы закон актларында һәм әлеге Карар белән билгеләнгән нормативлар буенча федераль, региональ һәм җирле салымнарны һәм җыемнарны түләүдән кергән керемнәр хисабына.

5 статья

2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен ноль сум күләмендә билгеләргә.

6 статья

1. Авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге Карарга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

2. Авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге Карарга 7 нче кушымта нигезендә расларга.

7 статья

Авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын расларга:

2020 елга әлеге Карарга 8 нче кушымта нигезендә;

2021 елга әлеге Карарга 9 нчы кушымта нигезендә;

2022 елга әлеге Карарга 10 нчы кушымта нигезендә.

8 статья

Олыяз авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына резерв фондының чик күләмен авыл бюджеты чыгымнарының 3%ы күләмендә билгеләргә.

9 статья

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә җирлекләргә финанс ярдәменең район фондыннан Кукмара муниципаль районы бюджетыннан керә торган дотацияләрне исәпкә алырга:

2020 елга 978100 сум күләмендә,
2021 елга 949800 сум күләмендә,
2022 елга 910000 сум күләмендә.

10 статья

Авыл җирлеге бюджетында хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен бирелгән субвенцияләр күләмен исәпкә алырга:

2020 елга 134400 сум күләмендә,
2021 елга 135900 сум күләмендә.,
2022 елга 141400 сум күләмендә.

11 статья

Авыл җирлеге башкарма комитеты 2020 елда һәм 2021 – 2022 елларда муниципаль хезмәткәрләр, бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм оешмалары хезмәткәрләре санын арттыруга, шулай ук аларны тотуга киткән чыгымнарны арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

12 статья

Авыл җирлеге бюджетын үтәгәндә әлеге Карар белән расланган керемнәрнең гомуми күләменнән тыш фактта алынган керемнәр, әлеге Карарга үзгәрешләр кертмичә, авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, муниципаль үзләштерүләрне алмаштыруга, муниципаль бурычларны түләп бетерүгә, шулай ук аларны үтәү өчен Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 217 статьясындагы 3 пунктында каралган күләмдә бюджет ассигнованиеләре җитмәгән очракта гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлтелә.

Олыяз авыл җирлеге бюджетын үтәгәндә әлеге Карар белән расланган керемнәрдән тыш фактта алынган субсидияләр һәм субвенцияләр, әлеге Карарга үзгәрешләр кертмичә, җыелма бюджет язмасына (роспись) үзгәрешләр кертеп, субсидияләр һәм субвенцияләр бирү максатларына бәйле чыгымнарны арттыруга юнәлдерелә.

13 статья

Авыл җирлеге бюджет учреждениеләре тарафыннан эшмәкәрлек һәм башка керем китерә торган эшчәнлектән алынган акчалар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Кукмара муниципаль районы буенча территориаль бүлегендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә рәсмиләштерелгән генераль рөхсәтләр нигезендә аларның ачылган шәхси счетларында исәпкә алына дип билгеләргә.

Бюджет учреждениеләре тарафыннан үтәлеше эшмәкәрлек һәм керем китерә торган башка төр эшчәнлек акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган шартнамәләр төзү һәм түләү расланган керемнәр һәм чыгымнар сметалары чикләрендә башкарыла дип билгеләргә.

2020елда һәм 2021 – 2022 елларда авыл җирлеге милкендә булган һәм мәдәният, сәнгать, сәламәтлек саклау, мәгариф бюджет учреждениеләренә, шулай ук архив учреждениеләренә оператив идарәгә тапшырылган мөлкәтне арендага бирүдән кергән керемнәр авыл җирлеге бюджеты керемнәре составына кертелә һәм әлеге Карар нигезендә бюджет йөкләмәләрен үтәү өчен файдаланыла дип билгеләргә.

14 статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының Кукмара муниципаль районы буенча территориаль бүлеге килешү нигезендә һәм түләүсез нигездә Олыяз авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

15 статья

Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә.

16 статья

Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмати стендларына элү юлы белән игълан итәргә.

Олыяз авыл
җирлеге башлыгы /Р.Ф.Маликов/

ОГРН 1021607754651
ИНН 1623001672